Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре, мәйдан Советы, 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**" 15 " гыйнвар 2025 ел** **№ 145**

**Арча шәһәр Советының "Җир салымы турында" 2022 елның 17 августындагы 79 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (11.01.2023 N 90, 29.11.2023 № 115, 17.09.2024 № 135, 22.11.2024 №138 үзгәрешләр белән)**

2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Арча шәһәр Советы карар кабул итте:

1. Арча шәһәр Советының "Җир салымы турында" 2022 елның 22 августындагы 82 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата, моңа әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләре һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләренә карата 0,18 процент;».

2) 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм аерым Россия Федерациясе закон актлары», әлеге пунктта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, аларның һәркайсының

кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләренә карата 0,18 процент;».

2. Әлеге карарның 1 пунктының гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. 01.01.2025 елдан Арча шәһәр Советының 22.11.2024 №138 «Арча шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2022 елның 17 августындагы 79 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г.Нуриев